# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк торак пунктында
2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 31 октябрендәге 2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

« 1)Үрнәк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урман урамындагы авыл эчендәге юлны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү));

-2) Үрнәк торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампаларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (эшләр өчен түләү) һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр));

-3)Үрнәк торак пунктындагы зират территориясен төзекләндерү ( территорияне чабу, эш өчен килешү буенча түләү)"»

3. Өчкүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өчкүл авыл җирлеге башлыгы
Спас муниципаль районы Н.В. Емелюшина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637005577
ОГРН 1061677000395